**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган мәктәп туры олимпиада биремнәренең җаваплары**
**2021/2022 уку елы, 11 нчы сыйныф**

*Максимальный балл –107 б.*

1. **Прочитай текст, назови (2 б.), вместо многоточий допиши пропущенные слова (по 2 балла =16 баллов) и**

***Тукай татар әдәбиятында биек бер тау.***

Тукай дөньяда 27 яшькә кадәр ГЕНӘ яшәде, ләкин ул КЫСКА гомерен дә зур итеп, мәгънәле итеп үткәрде. Иҗтимагый һәм СӘЯСИ тормышта ул катнашмаган бер генә өлкә дә булмагандыр.

Барыннан да бигрәк ул яза. Әйтерсең лә, гомеренең кыска, вакытының АЗ икәнен тоеп, уйлаганын әйтеп бетерергә ашыга. Татар әдәбиятының АЛТЫН фондына кергән “Шүрәле”, “Су анасы”, “Кисекбаш” әле бүген дә композиторлар, рәссамнар, драматурглар иҗатына, опера һәм балет артистларына илһам биреп тора.

Безнең әдәбиятта Тукай БИК биек бер тау булып күтәрелеп тора. Чөнки Тукай - үз халкының РУХИ байлыгы чагылышы ул. Тукайның тормышы – күз яшьләре белән, фикер һәм җыр белән ТУЛЫ тормыш. Тукай яши, яшәячәк.

(Г.Ахунов)

**напиши ответы на вопросы (**по 2 б., макс. б. -10)

1) Тукай кайда туган, кайларда яшәгән? Шул турыда нәрсәләр беләсең?

2) Ни өчен шагыйрьнең гомере кыска булган?

3) Тукайның тормышы нинди сүзләр аша бирелә?

4) Ул нинди жанрларда иҗат иткән?

5) Тукай татар операсы һәм балеты тарихында нинди роль уйный?

**Җаваплар:**

*1) Г. Тукай Казан артында туган. Бик иртә әти-әнисез калган. Башта Кырлайда яшәгән, аннан соң апасы Уральскига алган. Уральски шәһәрендә мәдрәсәдә укыган, типографиядә эшләгән. Аннан соң Казанга кайткан.*

*Якынча җавап шулай булырга мөмкин.*

*2) Ул бик нык авырый, анда туберкулез авыруы була.*

*3) Кыска, зур итеп, мәгънәле.*

*4) Проза, публицистика, поэзиягә караган әсәрләр иҗат итә. (Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр, поэмалар, әкиятләр иҗат итә).*

*5. Тукайның әсәрләре (“Шүрәле”, “Су анасы”, “Кисекбаш”) нигезендә опера язылa һәм балет куела.*

**Макс. балл – 28.**

**2. Из слов составь предложения (по 2 б., макс.б. -10).**

1).Инсаф, спорт, мәктәпнең, беркөнне, залында, тапты, телефоны, кесә. 2). халкының, сабантуй, иң, татар, бәйрәме, яраткан. 3). һәйкәл, Кремле, Казан,тарихи. 4). музее, авылында, ачылган, 1979 нчы, Тукай, Кырлай, елда. 5). урманчы, кирәк, өчен, яратырга, булыр, чын, табигатьне

| № | **Предложения** | **Макс.кол-во баллов - 10** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | Инсаф беркөнне мәктәпнең спорт залында кесә телефоны тапты. | **2** | |
| 2. | Татар халкының иң яраткан бәйрәме – сабантуй. | **2** | |
| 3. | Казан Кремле - тарихи һәйкәл. | **2** | |
| 4. | 1979 нчы елда Кырлай авылында Тукай музее ачылган. | **2** | |
| 5. | Чын урманчы булыр өчен табигатьне яратырга кирәк. | **2** | |

**3. Переведи на татарский язык и запиши.**

1. Елабуга – старинный городок в Татарстане 2. Здесь родились: кавалерист-девица Н.А.Дурова, художник И.И.Шишкин, известный ученый психиатр В.М. Бехтеров, маршал Советского Союза Л.А. Говоров и другие известные люди. 3. Эта земля хранит память об отрядах Емельяна Пугачева, о писателях А.Н.Радищеве и В.Г.Короленко, о командире гражданской войны В.И. Чуйкове. 4. В Великую Отечественную войну Елабуга послала на фронт тысячи бойцов. 5. Елабуга включена в число исторических городов.

.

| № | **Предложения** | **Макс.кол-во баллов - 15** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | Алабуга Татарстандагы борынгы шәһәрчек. | **3** | |
| 2. | Монда кавалерист кыз Н.А. Дурова, рәссам И.И. Шишкин, танылган галим-психиатр В.М. Бехтеров, Советлар Союзы маршалы Л.А. Говоров һәм башка танылган ешеләр туган. | **3** | |
| 3. | Бу җир Емельян Пугачев отрядлары, язучылардан А.Н.Радищев, В.Г.Короленко, гражданнар сугышы командиры В.И. Чуйков турындагы истәлекәрне саклый. | **3** | |
| 4. | Бөек Ватан сугышы елларында Алабуга фронтка меңләгән сугышчыларын озата. | **3** | |
| 5. | Алабуга тарихи шәһәрләр исемлегенә кертелгән. | **3** | |

**4. Образуй новые слова из корня *күз* с помощью аффиксов** (по 2 б. закаждое слово, макс. б. - 14).

Күз, күзле, күзсез, күзлек, күзәнәк, күзлә, күзәт, күзәтүче.

**5. Выберите и вместо многоточия ставьте фразеологизм (2б.).**

***Әни пешергән бәлеш ... булган.***

1) сүзсез калырлык
2) йөз чөерерлек

3) баш әйләнерлек

**4) телне йотарлык**

**6. Найди грамматический правильное продолжение предложения (2 б.)**

Яңгыр ява, ... .

1) ләкин без бернәрсә белмибез.

2) шунда кичә башланды.

3) шул вакытта кыш та җитте.

**4) шулай да без юлга чыктык.**

**7. Вместо многоточия вставь подходящее падежное окончание (4 б.).**

1) эшНЕ дәвам итәргә

2) эшТӘ/КӘ ярдәм итәргә

3) эшКӘ игътибар итәргә

4) эшТӘН кайтып китәргә

**8. В какой последовательности нужно расставить предложения, чтобы получился текст? (***макс.б.- 4)*

А) Ашый торган ризыкта витаминнар булуы бик мөһим.

Ә) Һәркем сәламәт булу өчен тырышырга тиеш.

Б) Шуңа күрә кешеләр ит тә, сөт ашамлыклары да, яшелчәләр дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш.

В) Сәламәт булырга теләсәң, иң беренче чиратта яхшы тукланырга кирәк.

1) Ә, В, Б, А

2) В, Ә, Б, А

**3) Ә, В, А, Б**

4) В, Ә, А, Б

**9. Решай и запиши ответы логических задач на татарском языке (по 4 б., макс. 8 б.) .**

1.Дүрт малай спорт белән шөгыльләнә: йөзү, йөгерү, сикерү, тимераякта шуу. Исемнәре: Марат, Илдар, Гали, Васил. Васил тимераякта шумый, Гали йөзү

һәм тимераякта шуу белән шөгыльләнми, ә Марат йөгерешче. Кем нәрсә белән шөгыльләнә?

2.Ике салай гитарада, бер малай мандолинада уйнарга өйрәнә. Вәкил һәм Камил, шулай ук Камил һәм Фоат төрле уен коралларында уйный. Кем нәрсәдә уйный?

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) (8) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| 1. | Марат – йөгерү, Илдар – тимераякта шуу, Гали – сикерү, Васил – йөзү белән шөгыльләнә. | **4** | |
| 2. | Вәкил гитарада, Камил мандолинада, Фоат гитарада уйный. | **4** | |

**10. Составь рассказ из 8-10 предложений по теме “Минем тормышымда интернет” (макс. -20 б.).**